# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргала торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**02 ноябрь, 2020 ел.** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 01 ноябрендә 11 сәгатьтә, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргала авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 56 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 41, бу 73 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 41 катнашучы тавыш бирде;
"Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Каргала авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргалы авылы территориясендә яшәү урыны

буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булмаган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Алынган акчаларны жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Каргалы торак пунктында материаллар сатып алып, зиратларны чистарту һәм ремонтлау (койма) (килешү буенча эшләр өчен түләү);

4. Гамәлдән чыгару:

4.1 «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргалы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2020 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы карар;

4.2 «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Каргалы торак пунктында» 2020 елның 1 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карары.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М. Емельянова